# Әбиемә

Резеда Шамсуллина



90 булыр иде минем әбиемә,
Җәйнең матур июль аенда.
Алып китте аны язның җилле көне,
Мәңгелеккә бакый дөньяга.

Белсәң иде ничек җаным бәргәләнде,
Сизгән сыман синсез калуны.
Күбәләктәй очты күңелкәем,
Яннарыңа, белми талуны.

Йөрәгемне телеп өшетте:
Син юк дигән ачы хәбәр.
Шул мизгелдән алып өзелде
Балачак иленә булган жепләр.

Синсез сүнде өйнең нуры,
Син булмагач ямансу.
Үстергән гөлләрең дә бит,

Карый тәрәздән моңсу.

Көн дә хәзер хәтеремне барлыйм:
Капка ачып, яшел келәмгә атлыйм,
Өй ишегеннән тизрәк кереп,
Колач җәеп сине кочаклыйм.

Өстәл тулы камыр ашы синең,
Авыз итсәң - телне йотарлык.
Мичтә пешкән коймак тәмен,
Гомергә дә тугел онытырлык.

Кич утырудан керү үзе рәхәт,
Чуар япкыч астында иң тәмле сый:
Яңа сауган сөт һәм ипи,
Сеңлем белән мине каршылый.

Киң күңелле булганга син,
Өй тулы кунак иде.
Һәрберсенә күрсәттең син,
Ачык йөз һәм мул табын.

Сабыр төбе - сары алтын диеп,
Син түзем булырга өндәдең.
Язмыш каты сынаса да,
Син, әби, бирешмәдең.

Өйрәткән догаларың,
Онытылмас беркайчан.
Кылган игелегең өчен,
Зурласын сине Ходам.

Кадерле әбием минем,
Урының булсын оҗмах түрендә,
Тынычлык тапсын җаның.
Син мәңгегә безнең йөрәкләрдә.

Күп шул әйтер сүзләрем.
Сүздән мөһим - догалар,
Минем бик зур теләгем -
Рухыңны шат кылсын Тәңрем.

